МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

14.12.2015 № 572

**“Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарына билгеләнгән вакытта гражданнар үзләренең керемнәре турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре турында белдерергә тиеш, һәм шулай да дәүләт гражданлык хезмәте урынын биләгән вакытта дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре үзләренең керемнәре турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре турында белдерергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннары Исемлеген раслау турында” 09.01.2014 № 6 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгына үзгәрешләрне кертү турында**

“Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон бирү актларына үзгәрешләрне кертү турында” 2014 ел 22 нче декабрь № 431-ФЗ Федераль законына, “Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләренең кайберләре турында” 2015 ел 8 нче март № 120 Россия Федерациясе Президенты Указына һәм “Коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләрне кертү турында” 2015 ел 23 нче март № УП-308 Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп, б о е р ы к б и р ә м:

1. “Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарына билгеләнгән вакытта гражданнар үзләренең керемнәре турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре турында белдерергә тиеш, һәм шулай да дәүләт гражданлык хезмәте урынын биләгән вакытта дәүләт гражданлык хезмәте хезмәткәрләре үзләренең керемнәре турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре турында белдерергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннары Исемлеген раслау турында” 09.01.2014 № 6 Татарстан

Республикасы ГТХМ боерыгына (05.05.2014 № 205 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) боерык исемен “Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарына билгеләнгән вакытта гражданнар үзләренең керемнәре, чыгымнары, турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында белдерергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннары Исемлеген раслау турында” редакциясендә язып бирергә;

б) боерык преамбуласында “гражданнар билгеләнгән вакытта һәм” сүзләрен чыгарырга;

в) югарыда әйтелгән боерыкның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә язып бирергә:

“1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында үзләренең керемнәре, чыгымнары, турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында белдерергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннарын били торган беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте урыннары Исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.”

г) югарыда әйтелгән боерыкның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә язып бирергә:

“2. Татарстан Республикасы ГТХМ да Исемлеккә кертелгән дәүләт гражданлык хезмәтен били торган гражданин һәр елны керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында билгеләнгән вакыт эчендә белдерер өчен үзенең чыгымнары, шулай да хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының чыгымнары турында җир бүлемтеген, башка күчемсез милекне, транспорт чарасын, бәяле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайлары белән) сатып алу буенча үзе, хатыны (ире) һәм (яисә) яше җитмәгән балалары белән мәгълүматларны күрсәтү елы (алга таба – отчет чоры) алдыннан булган календарь елы эчендә, шундый килешүләрнең гомуми суммасы биредәге шәхеснең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән соңгы өч ел эчендә артык булса, һәр килешү буенча, һәм акчаларны алу чыганаклары сәбәпле шул башкарылган килешүләр турында мәгълүматларны күрсәтергә тиеш.

д) югарыда әйтелгән боерыкның 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә язып бирергә:

“3. Татарстан Республикасы ГТХМ Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә “Коррупциягә каршылык турында” 2008 ел 25 нче декабрь Федераль законының 12 нче мәкалә кагыйдәләрен дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә аңлатып торырга, шул исәптән мәҗбүри рәвештә дәүләт гражданлык хезмәткәрен Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтеннән чыгарыр алдыннан”.

е) югарыда әйтелгән Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган Исемлек исемен түбәндәге редакциядә язып бирергә:

“Татарстан Республикасы дәүләт граждалык хезмәтенең урыннарында булган дәүләт гражданлык хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында, шулай да хатынының (иренең) һәм яше җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм милек йөкләмәләре турында белдерергә тиеш булган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең урыннар исемлеге”.

2. Министрлыкның хокук тәэмин итү бүлеге башлыгы С.В. Хәлиловка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында бирелгән боерыкның дәүләт теркәлүен һәм алга таба аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокук мәгълүматы рәсми сайтында (pravo.tatarstan.ru) рус һәм татар телләрендә урнаштыру буенча эшне оештырырга.

3. Министрлыкның информация бүлеге башлыгы Е.Б. Демчакка бирелгән боерыкның рус теленнән татар теленә тәрҗемә итүен тәэмин итәргә.

4. Бирелгән боерыкны министр урынбасарларына, Татарстан Республикасы ГТХМ аппараты структура бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

5. Бирелгән боерыкның башкарылу контролен министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р. Җ. Хәбибуллин